| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.10.2023 1267

«Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 07 сентябрендәге 1012 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Техник хата җибәрелү сәбәпле, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 07 сентябрендәге 1012 номерлы карарының 1.2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм 1.2 пунктны яңа редакциядә расларга:

«1.2. җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең 1.2. 10 (ун) проценты:
- торак пунктлар җирләренә кертелгән һәм шәхси ярдәмче хуҗалык (ШЯХ) өчен кулланыла торган урыннарны;
- бакчачылык, яшелчәчелек өчен;
- сәүдә объектлары тезү өчен;
- банк, иминият һәм биржа эшчәнлеге объектлары төзү өчен;
- җәмәгать туклануы объектлары өчен;
- автосервис, юл буе сервисы объектлары һәм автозаправка станцияләре тезү өчен;
- административ биналарга һәм офисларга;
кунакханә төзү өчен;
- ачык автотранспорт тукталышы тезү ечен;
- иҗтимагый-эшлекле әһәмияттәге объектлар өчен;
- ял, туризм, физкультура-савыктыру һәм спорт эшчәнлеген оештыру өчен».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә калдырырга.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Ә.К.Габдуллин